БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 июнь 2024 ел № 256

**«Норма» сәнәгать паркы һәм «Балтач» агросәнәгать паркы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен арендага алу өчен айлык түләүләр буенча ташламалар билгеләү турында**

Инвестицияләрне, инновацион технологияләрне җәлеп итү, шулай ук предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, житештерүне, сәнәгатьне үстерү, Балтач муниципаль районы территориясендә эш урыннарын арттыру максатында, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законнарга таянып, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектын аккредитацияләү турындагы таныклык гамәлдә булган вакыт эчендә, «Норма» сәнәгать паркы һәм «Балтач» агросәнәгать паркы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен арендалаган өчен аренда түләвеннән тулысынча азат итү юлы белән айлык түләүләр буенча ташламалар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен арендага алучыларга җир кишәрлекләре өчен айлык аренда түләве буенча ташламалар 2024 елның 01 июленнән башлап бирелә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән, җир кишәрлекләрен арендага алып, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре буенча кулланмаучылар аренда түләвен тулы күләмдә кертәләр.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район советы рәисе Р.Р.Нотфуллин